Республика Татарстан
Старо-Имянское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районы Иске Имән
авыл жирлеге

КАРАР
17.09.2018

КАРАР
№ 95

**Референдум уздыруны инициацияләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Иске Имән авыл жирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл жирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Жирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда үзара салым кертүгә Иске Имән авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт итуче гражданнардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны жибәрү белән килешәсезме:

1)Ял вакытын оештыру һәм жирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкемән авылларында "Сабантуй", "Өлкәннәр көне", "Яңа ел" бәйрәмнәрен уздыру өчен бүләкләр алу;

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларында бәйрәм чаралары үткәрү өчен музыка апаратурасы алу;

2.) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларында яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру);

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларындагы памятниклар өчен краска сатып алу;

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларындагы ял итү урыннары төзү өчен тозелеше материаллары сатып алу;

- Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүчегә түләү);

- Торак пунктларда көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру.

3) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

-Сарсысаз-Тәкермән авылы өсен мотопомпа сатып алу;

-Сарысаз-Тәкермән авылы өчен янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

3. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларын кардан чистарту.

ӘЙЕ ЮК».

2.Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

3. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Советы
рәисе Р.Ә.Исламова